**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципаль районы**

Ленин ур., 22 й., Азнакай ш., 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**"30" сентябрь 2022 ел** **№289**

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2012 елның 20 декабрендәге 278 номерлы «Азнакай муниципаль районы торак пунктлары территорияләрен санитар чистартуның генераль схемасы турында» карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы торак пунктлары территорияләрен санитар чистартуның Генераль схемасына үзгәреш кертү турында (2018 елның 13 июлендәге 141 номерлы редакциясендә)

«Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 343-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән карар бирә:

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2012 елның 20 декабрендәге 278 номерлы «Азнакай муниципаль районы торак пунктлары территорияләрен санитар чистартуның генераль схемасы турында» карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы торак пунктлары территорияләрен санитар чистартуның Генераль схемасына (2018 елның 13 июлендәге 141 номерлы редакциясендә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 11 бүлегендәге 15 терминның һәм билгеләмәләрнең абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Калдыклар урнаштыру объектлары-калдыкларны, шул исәптән җир асты байлыкларыннан файдалану калдыкларын урнаштыру өчен билгеләнгән махсус җиһазландырылган корылмалар («Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-I номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә кулланылырга тиешле ачык һәм сыйдырышлы тау токымнарын саклау объектларыннан гайре), калдыкларны саклау объектларын һәм калдыкларны күмү объектларын үз эченә ала;».

2. Әлеге карар 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура буенча урынбасары
Р.Р. Ханнановка йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов